| | | |
|---|---|---|
| МИНИСТЕРСТВО СЕЛЬСКОГО ХОЗЯЙСТВА И ПРОДОВОЛЬСТВИЯ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АВЫЛ ХУҖАЛЫГЫ ҺӘМ АЗЫК-ТӨЛЕК МИНИСТРЛЫГЫ |

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

29.08.2016 г.Казань № 162/2-пр

Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының 2016 елның 15 гыйнварындагы “2016 елга Татарстан Республикасы агросәнәгать комплексына дәүләт ярдәме өчен федераль бюджеттан алына торган акчалар хисабына субсидияләр бирү тәртибен раслау турында” №1/2-пр боерыгына карата 16 кушымтага үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2012 елның 27 декабрендәге “Үсемлекчелек өлкәсендә авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә бәйле булмаган ярдәм күрсәтүгә Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына федераль бюджеттан субсидияләр бирү һәм бүлү кагыйдәләрен раслау турында” № 1431 карарын үтәү максатында б о е р ы к б и р ә м:

1. Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының 2016 елның 15 гыйнварындагы “2016 елга Татарстан Республикасы агросәнәгать комплексына дәүләт ярдәме очен федераль бюджеттан алына торган акчалар хисабына субсидияләр бирү тәртибен раслау турында” №1/2-пр боерыгына (16.02.2016 №15/2-пр, 21.03.2016 №45/2-пр, 13.04.2016 №73/2-пр, 11.05.2016 №99/2-пр, 27.05.2016 № 114/2-пр, 30.05.2016 № 117/2-пр боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) карата 16 кушымтага түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Кушымтаның 4, 5, 6, 8 пунктларын түбәндәге эчтәлекләрендә бәян итәргә:

“4. 2015 елда авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләрендә милектә һәм (яки) аренда шартларында орлыклык бәрәңге һәм ачык грунт яшелчәләренең чәчүлек мәйданнары булуы субсидияләр бирүнең шарты булып тора.”;

“5. Орлыклык бәрәңге һәм (яки) җимшәннәр һәм ачык грунттагы яшелчә культураларының орлыклары өчен билгеләнә торган чәчүлек мәйданнарына ия булган авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә субсидияләр җыелма мәгълүматка туры китереп, апробация актлары һәм (яки) Татарстан Республикасы буенча “Россия авыл хуҗалыгы үзәге” федераль дәүләт бюджет учреждениесе филиалы (алга таба – ТР буенча “Россельхозцентр” ФДБУ) тарафыннан 2015 елга таныкланган, орлыклык чәчүлекләрнең чәчүлек мәйданнарын раслый торган орлыклык чәчүлекләрне теркәү (алга таба – 2015 ел өчен орлыклык чәчүлекләрнең чәчүлек

мәйданнары турында мәгълүмат) нигезендә Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан 1 гектарга раслана торган ставкалар буенча бирелә.”;

“6. Ачык грунттагы яшелчә культуралары өчен биләнгән чәчүлек мәйданнарына ия булган авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә субсидияләр 2015 ел өчен чәчү нәтиҗәләре турындагы рәсми статистика хисабы шуңа нигезләнеп формалаштырылган чәчүлек мәйданнары турындагы мәгълүмат (алга таба – 2015 ел өчен чәчүлек мәйданнары турында мәгълүмат) буенча Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан 1 гектарга раслана торган ставкалар нигезендә бирелә.”;

“8. Шушы Тәртипнең 5 пункты нигезендә субсидияләр алу өчен авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык төлек министрлыгының Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсенә (алга таба – Идарә) түбәндәге документларны тапшыралар:

үзләренең түләү реквизитларын һәм почта адресын күрсәтеп, субсидияләр бирелү турында гариза;

2015 ел өчен орлыклык чәчүлекләренең чәчүлек мәйданнары турында мәгълүмат;

авыл хуҗалыгы культураларының орлыкларын китерүгә шартнамә күчермәсе (сатып алынган орлыкларны җитештерүдә алга таба сату өчен куллана торган авыл хуҗалыгы җитештерүчеләре өчен);

орлыклар өчен түләгәнлекне раслый торган түләү йөкләмәсенең күчермәсе (сатып алынган орлыкларны җитештерүдә алга таба сату өчен куллана торган авыл хуҗалыгы җитештерүчеләре өчен);

сатып алынган орлыкларга накладная күчермәсе (сатып алынган орлыкларны җитештерүдә алга таба сату өчен куллана торган авыл хуҗалыгы җитештерүчеләре өчен);

сатып алынган орлыкларның сыйфаты ярашлы булуы турындагы сертификат күчермәсе (сатып алынган орлыкларны җитештерүдә алга таба сату өчен куллана торган авыл хуҗалыгы җитештерүчеләре өчен);

орлыкларны Татарстан Республикасы чикләреннән керткәндә карантин сертификатының күчермәсе һәм фитосанитар контрольлек акты (сатып алынган орлыкларны җитештерүдә алга таба сату өчен куллана торган авыл хуҗалыгы җитештерүчеләре өчен);

милектә һәм (яки) аренда шартларында авыл хуҗалыгы культураларының чәчүлек мәйданнарына ия булуны раслый торган мәгълүмат;

ТР буенча “Россельхозцентр” ФДБУ филиалы тарафыннан еллар буенча таныкланган, җитештерелгән орлыкларның репродукциясен раслый торган мәгълүмат (үзләренең орлык материалын җитештерүдә алга таба сату өчен куллана торган авыл хуҗалыгы җитештерүчеләре өчен);

2015 елдагы уңыш орлыкларын сату турында авыл хуҗалыгы товар җитештерүчесе тарафыннан таныкланган мәгълүмат;

Министрлык раслаган рәвештә тиешле субсидияләр турында белешмә-исәпләмә.

Тапшырыла торган документларның күчермәләре авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре тарафыннан таныклана.”.

2. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча министрның беренче урынбасары Н.Л. Титовны җаваплы итеп билгеләргә.

Татарстан Республикасы Премьер-министры
урынбасары – министр М.Г. Әхмәтов.